ГЛАВА МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Майдан _______________

1

«2016 нчы елга Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге бюджеты турында» Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегендә яшәүчеләрнең 2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге бюджеты проектын халык алдында тыңлаулар уздыру юлы белән тикшерүдә катнашу хокукларын саклау максатыннан "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Мәйдан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан районының Мәйдан авыл җирлеге Советының "2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге бюджеты турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 26 ноябрендә 14.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

2.3. үткәрелү урыны - Мәйдан авылы, Совет ур., 55 йорт авыл мәдәният йортында;

2.4. Фикер алышкан мәсьәлә буенча гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү һәм тәкъдимнәр һәм кисәтүләр белдерелергә мөмкин булган адрес - Майдан

авылы, Совет урамы, 55 йорт, Мәйдан авыл җирлеге башлыгы Михеевка В.В. (эш көннәрендә - 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.5. чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү срогы - 2015 елның 22 ноябренә кадәр (тел 35-0-48).

3. Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетына:

3.1. “2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге бюджеты турында" Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлауларны гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда әзерләргә һәм үткәрергә;

3.2. гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Югары Ослан районының Мәйдан авыл җирлеге Советына халык алдында тыңлаулар, гавами тыңлаулар киңәшләре, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгаклау, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге бюджетының 2016 елга эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектын тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны, Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының "2016 елга Мәйдан авыл җирлеге бюджеты турында" Карары проектын Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В.В.Михеев